ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

2021 елның 23 июне Чистай шәһәре № 348

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 247 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә Чистай шәһәр прокуратурасының 2021 елның 21 июнендәге 02-08-01-2021 номерлы таләбен карап чыкканнан соң Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 247 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлекнең 2.5 пунктындагы 5 пунктчасыннан «опекун билгеләү турында опека һәм попечительлек органнарыннан белешмә - хокукый сәләтсез гражданның опекуны тарафыннан исәпкә алу турында гариза имзаланган очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлекнең 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә: «Опека һәм попечительлек органнарыннан опекун билгеләү турындагы белешмә - хокукый сәләтсез гражданның опекуны тарафыннан исәпкә алу турында гариза имзаланган очракта».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов